Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлегенең Татар Сарсазы авылында

**Халык җыены карары**

**2021 нче елның 17 нчы декабрендәге** **3 нче номерлы КАРАРЫ**

2003 елның 6 октябрендәге 131 нче номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 ст., 2004 елның 28 июлендәге 45 нче номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законының 35 ст. нигезендә Песәй авыл җирлегенең Татар Сарсазы авылы халык җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елда гражданнарның үзара салымын Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Татар Сарсазы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә кертергә, I һәм II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылар, тәрбиясендә балигъ булмаган балалары булган күп балалы гаиләләр һәм көндезге (көндезге) уку формасы студентлары өчен, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнарга 250 сум күләмендә билгеләргә
2. Җыелган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
    1. вак таш алу (китерү, тигезләү)
    2. кышкы чорда юлларны кардан чистарту
    3. агач кисү
    4. балалар мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру.
    5. задвижка сатып алу (сууткәргечкә кран).
3. Җыен нәтиҗәләрен Песәй авылы, Үзәк урам, 4 нче йорт адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында "Песәй авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга. www.mendeleevsk.tatar.ru
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Песәй авыл җирлеге Советы башлыгы В.И. Мөхәмәтгалеев